МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.03.2023 Казан ш № 216

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 июлендәге 516 номерлы боерыгы белән расланган Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 июлендәге 516 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016

№317, 22.06.2017 №406, 07.05.2018 №349, 18.09.2018 №885, 24.06.2019 №493, 12.11.2019 №992, 25.02.2020 №119, 14.07.2020 №516, 16.10.2020 №735, 31.08.2021 №624, 17.08.2022 №787, 12.01.2023 №15) боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 24 мартындагы 216 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 июлендәге 516 номерлы боерыгы белән расланган Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрP26

1.2 пунктта:

икенче-дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яки) эшче һөнәрләр, хезмәткәр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алган ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, белем алу чорында, шул исәптән алар 23 һәм аннан олырак яшенә җиткәнче, ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затлар; - белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлап чыкканда бер бирелә торга акчалата пособие, кием-салым комплекты, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер бирелә торган пособие, туклану өчен ел айлык пособие, кием-салым комплекты, аяк киеме һәм йомшак инвентарь сатып алуга ел саен бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән очракта;

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада белем алган ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, белем алу чорында, шул исәптән алар 23 һәм аннан олырак яшенә җиткәнче, ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затлар, – уку әсбаплары һәм язу кирәк-яраклары сатып алу өчен ел саен бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән очракта;

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында

белем алучы ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затлар, шул исәптән алар 23 һәм аннан олырак яшенә җиткәнче, инвалид балалар, инвалидлар, – айлык стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү очрагында;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән, әлеге мәгариф программалары буенча укытуны төгәлләгәнчегә кадәр, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затлар, – уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие, туклануга айлык пособие, кием-салым, аяк киеме һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очракта;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар һәм уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер ата-анасын югалткан, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар хисабына белем алучы затлар, - белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларны тәмамлап чыкканда бер бирелә торган акчалата пособие, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларны тәмамлап чыкканда кием-салым комплекты, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алу өчен акчалата пособие билгеләү өчен дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта.»;

3 бүлекнең 3.3.2.5 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.».